Нияз Сабиров

# МӘҮЛИД КИТАБЫ

Хузур - 1434/2013



www.darul-kutub.com

Мәүлид китабы. – Казан: Хузур, 2013. -64 бит.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең эксперт шурасы № 13-064 карары нигезендә бастырырга рөхсәт ителә.

Одобрено к печати решением № 13-064 экспертного совета ЦРО-ДУМ РТ

© Издательство «Хузур-спокойствие», 1434/2013

Формат 84x108 1/32 , печатных листов: 1,0;
бумага офсетная, печать офсетная, тираж 2 000 экз.
Издание выпущено при поддержке издательства “Культурные ценности”
г Казань, пр Победы, 30, тел.: 251 47 88 электронная почта: ipk_ppk@mail.ru

типография «Астор и Я» г Казань Ахтямова 13а
Отпечатано в соответствии с предоставленным электронным материалом.

www.darulkutub.com


بسم الله الرحمن الرحيم

www.darul-kutub.com

# МӘҮЛИД МӨБАРӘК БУЛСЫН!

**Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!**

**Мөхтәрәм дин кардәшләребез!**

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык мөселманнарны да Мәүлид бәйрәме белән ихластан котлыйм!

“Мәүлид” – туу, туган вакыт мәгънәсен аңлата. Мәүлид кичәсе дөньяга соңгы пәйгамбәр буларак җибәрелгән сөекле Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) туган көне. Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) туган вакыты милади исәпнең 571 нче елына туры килә. Мәүлид - рабигыләүвәл аеның 11-12 нче көннәре арасындагы кичә. Коръәндә әйтелә: *“(Әй, Мөхәммәд) Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек”* (“Әнбия” сүрәсе, 107 нче аять). Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) тормышы, камил холкы һәр мөселман өчен өлге, үрнәк булып тора, нәсыйхәтләре калебләребезне ныгыта, күңелләребезне нурлы итә. Хәдисләре гыйлемле булырга, сабырлыкка, юмартлыкка өйрәтә.



www.darulkutub.com

Мәүлид кичәсендә догалар уку, тыңлау, дини мәҗлесләр корып салаватлар әйтү, хәер-догалар өләшү – Бөек Раббыбыз һәм Аның Рәсүленә (с. г. в.) карата ихласлыгыбызны күрсәтә. Пәйгамбәребез (с. г. в.) туган кичәне хөрмәт итү булып тора. Мәүлид кичәсе бер-беребезгә карата кардәшлек хисләрен ныгыту, хөрмәт итүне арттыру көне дә.

Шушы күркәм Мәүлид кичәсендә шөкрана кылыйк, дин кардәшләребез белән бергә Пәйгамбәребезгә (с. г. в.) багышлап һәм бер-беребезгә иминлек, бәрәкәт сорап догалар кылыйк. Барчабызга да Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләнең рәхим-шәфкате язсын! Өммәтебезгә Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) сөннәтенә ияргән хәлдә яшәргә насыйп итсә иде!

**Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**

## Мәүлид бәйрәмен үткәрүнең дөреслегенә дәлилләр

**Беренче дәлил:** Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) мәүлиден үткәрү Аллаһ тарафыннан сайланган пәйгамбәргә шатланудыр, хәтта шундый шатлык аркасында кәфер дә файда тапкан.

Тугызынчы дәлилдә без бу сорауны тирәнрәк карап китәрбез, чөнки асылда бу сораулар охшаш, гәрчә хәтта дәлилләрне китерү ысуллары аерылсалар да, без үзебезнең бу тикшерүебездә, кабатлауны булдырмас өчен, шул ысулны кулландык.

Бохари риваять иткән хәдисләр җыентыгында хәбәр ителгәнчә, Әбү Ләһәбнең һәр дүшәмбе көнендә газаплары җиңеләйтелә, чөнки ул Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тууы хакында шатлыклы хәбәр китергән Сувайбаны коллыктан азат иткән. Әл-Хафиз Шәмседдин Мөхәммәд бине Насретдин әд-Димашкый бу хакта болай дигән: “Хәтта шундый кабәхәт, кәфер булган кешегә дә (һәм Коръәндә дә аның турында “Тәббәт” сүрәсенең 1нче аятендә: *“Әбү Ләһәбнең ике кулы корысын һәм һәлак булсын!”* дип әйтелгән ), шулай ук, бу кешегә мәңгелек җәһәннәм вәгъдә кылынуына карамастан, җәһәннәмдәге газап һәр дүшәмбе көнендә җиңеләйтелә, чөнки ул Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тууына шатланды. Шуңа күрә, гади мөселман кешесенең хәле нинди булырга тиеш, ул бит гомере буе



www.darul-kutub.com

Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тууына (мәүлиденә) шатланып яшәде һәм бер Аллалык динендә, исламда вафат булды?!"

Бохари үзенең "сахих" риваятендә китерелгән бу кыйсса "Никах" турындагы бүлектә китерелә һәм ул хәдис мөрсәлдер[1]. Шул ук кыйссаны әл–Хафиз бине Хәҗәр "Фатхул Бәри" китабында риваять итте. "Әл-Мөсәннәф"ендә имам Габдеррәззак әс-Синаний, үзенең "Әд-Дәләлү" китабында әл-Байхакий, "Әл-Бидая вәән-нихая" китабында Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) тормышын тасвирлаган өлешендә бине Касир, "Хадаику әл-Әнвәри" китабында Мөхәммәд бине Гомәр Бахрак, "Шәрхе әс-Сөннәт" китабында әл-Хафиз әл-Багави, "Әр-Равду әл-Өнөфи" китабында бине Хишам һәм әс-Сөхәйли, "Бәхҗәтү әл-мәхәфили" китабында әл-Гамири шуны ук язганнар.

Бу кыйсса мөрсәл булса да, ул барыбер асылда кабул ителә, чөнки бу кыйссаны Бохари риваять итә һәм шулай ук күпчелек ислам галимнәре шушы җыентыкка таяналар. Бу хәдистә хәләл яки харам турында әйтелми, ә фазыйләтләр (мәнәкыйб) һәм хасыятләр (Хасааис) турында әйтелә. Ә шәкертләр һәм шаригать кануннарын өйрәнеп килгән кешеләр, фазыйләтләр һәм әхкәмнәр арасындагы дәлилләр китерүдә аерманы бик яхшы беләләр.

---

[1] *Мөрсәл* – "калдырылган", аны тапшыручылар чылбырында сәхәбә исеме булмаган хәдис.

www.darul-kutub.com

Аларның игелекле гамәлләре өчен кәферләргә файда китерү мәсьәләсе буенча, илаһият галимнәренең төрлечә фикерләре бар. Бу хезмәтнең максаты аларны җентекләп тикшерү түгел. “Сахих” китабында китерелгән бу мәсьәләнең нигезе – Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үтенече буенча, Әбү Талипның тәкъдирен җиңеләйтү.

**Икенче дәлил.** Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) үзенең туган көнен үзе дә зурлаган, туган көне өчен Аллаһка зур рәхмәтен белдергән, ул аны Аллаһның Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бүләк иткән бик олы нигъмәте итеп кабул иткән, Аңа бу дөнья тормышы төзеп бүләк иткәне өчен чиксез рәхмәтле булган. Чөнки, Аллаһның бу рәхмәте, Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бу дөньяга килүе аркасында, җирдәге бар җан ияләре дә зур шатлыкка ия булганнар, бәхеткә ирешә алганнар. Туган көнен олылауны Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) ураза тотып билгеләп үткән. Бу турыда Мөслимнең Әбү Катада тапшырган хәдисендә болай дип әйтелә: “Пәйгамбәрдән (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) дүшәмбе көнне ураза тоту турында сорагач, ул шулай дип җавап биргән: *“Дүшәмбе – минем туган көн һәм бу көнне миңа вәхи иңдерелде”*. Аллаһ Рәсүленең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) бу сүзләре шундый мәгънәгә ия: димәк, аның туган көнен, ягъни, дүшәмбе көннәрен билгеләп үтү мөмкин гамәл, тик аны бәйрәм итү төрлечә булырга

мөмкин. Бу риваять Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көнен билгеләп үтү, нинди рәвештә булуына карамастан – ураза тотып билгеләнеп үтәме ул, әллә инде сый әзерләп башка кешеләрне җыю, анда Пәйгамбәрне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) искә алу, аңа салаватлар әйтү, аның турында, күркәм әхлак сыйфатлары, өстенлекләре һәм камиллекләре турында төрле хикәятләр сөйләү һәм тыңлау рәвешендәме, - рөхсәт ителгән гамәл булуын дәлилли.

**Өченче дәлил:** Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) дөньяга килүенә шатлык белдерү, Аллаһы Тәгаләнең шул сүзләре бунча, - тиешле гамәл:

قُلْ بِفَضْلِ اللّهِ وَبِرَحْمَتِهِ فَبِذَلِكَ فَلْيَفْرَحُواْ

(Мәгънәсе): *"Ий Мөхәммәд г-м! Кешеләргә Аллаһның юмартлыгы вә рәхмәте илә иңдерелгән Коръән белән сөйлә һәм аларны Коръән белән гамәл кылырга өндә! **Коръән иңдерелгән өчен һәм аның белән гамәл кылганнары, Аның рәхмәтләре өчен шатлансыннар!"*** (10-чы сүрә, "Юныс", 58 аять). Аллаһы Тәгалә безгә Үзенең рәхмәтләре өчен шатланырга кушкан, ә Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) – Аның кешеләргә кылган рәхмәтләренең иң зурысы. Чөнки Раббыбыз шулай дигән:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلاَّ رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ

(Мәгънәсе): ***“Ий Мөхәммәд г-м, Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек”*** (21-че сүрә, “Пәйгамбәрләр”, 107 аять).

**Дүртенче дәлил:** Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) инде күптән үк булган дини вакыйгаларны да игътибарсыз калдырмаган. Ул датаның килеп җитүе, бу вакыйганы кабат искә төшерү, билгеләп үтү һәм олылау өчен яхшы мөмкинлек бирү өчен хезмәт иткән. Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) мондый кагыйдәләрне шәхсән үзе урнаштырган, бу турыда сахих хәдистә әйтелә: *“Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Мәдинәгә килгәч, ул яһүдиләрнең Гашура көнендә ураза тотканнарын күргән. Ул алардан моның сәбәбен сораган һәм алар: “Бу көнне Аллаһ Муса (аңа Аллаһның сәламе булсын!) пәйгамбәрне коткарып калып, фиргавенне*[2] *суда батырып үтергән. Шуңа күрә без, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән, бу көнне ураза тотабыз”, - дип җавап биргәннәр. Моны ишеткәч, Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!): “Без Муса пәйгамбәргә (аңа Аллаһның сәламе булсын!) сезгә караганда якынрак, безнең аңа хокукыбыз сезнекеннән күбрәк”, - дигән һәм шул көннән башлап Гашура*[3] *көнен ураза тотып олылый башлаган, башка мөселманнарга да бу көнне ураза тотарга кушкан.*

---

2 *Фиргавен* – Борынгы Мисыр хакиме.

3 *Гашура* – һиҗри тәкъвим буенча мөхәррәм аеның унынчы кичәсе.

**Бишенче дәлил:** Изге мәүлид мөселманнарны Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) салават әйтергә һәм сәлам җиткерергә чакыра, болар да Аллаһы Тәгаләнең сүзләре буенча, башкарылырга тиешле гамәлләр:

إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ
يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً

(Мәгънәсе): ***“Аллаһ үзе вә фәрештәләре пәйгамбәр г-мгә салават әйтәләр, ий мөэминнәр, сез дә пәйгамбәргә салават әйтегез һәм тырышып сәлам җиткерегез”*** (33-чы сүрә, “Әхзаб (Гаскәрләр)”, 56 аять).

Ә Шәригать таләп иткәннәрне башкарырга чакыручы гамәлләр – дин таләп иткән гамәлләр булып саналалар һәм Шәригатькә туры киләләр. Аллаһның Рәсүленә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) салават әйтүдә күпме пәйгамбәр ярдәме һәм файда бар, ә бит аларны санап та, каләм белән язып та бетерергә мөмкин түгел!

**Алтынчы дәлил:** Изге мәүлид вакытында мөселманнар гүзәл Пәйгамбәребезне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) искә алалар, аның могҗизаларын, тормышын бәян итәләр һәм алар белән танышалар. Ә безгә Аллаһ Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) һәм аның гамәлләре белән танышырга, аңа тәкълид итәргә, аңа охшарга тырышырга, аның гамәлләрен үрнәк итеп алырга, аның могҗизаларына ышанырга, галәмәтләрен акларга кушылмаганмы?! Ә бит

мәүлид турындагы китаплар бу максат һәм таләпләргә тулысынча җавап бирәләр.

**Җиденче дәлил -** аның камил сыйфатлары һәм мактарлык игелекле холкы турында сөйләп, аңлатып, Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) алдындагы бурычыбызның бик кечкенә генә өлешен булса да башкарып, аның өчен әҗерен алу. Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) заманында шагыйрьләр Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) янына килеп, аңа багышланган мәдхияләрен аңа укый торган булганнар. Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аларның бу эшеннән бик канәгать була торган булган һәм бу гамәлләрне хуплаган. Шуннан соң ул аларга истәлекле ниндидер бер әйбер бүләк иткән, аларның гозерләрен үтәгән, аларга күп игелекләр эшли торган булган. Әгәр дә Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аны мактап язган шагыйрьләрдән канәгать булган икән, аның бик зур өстенлекләрен җыйган һәм сөйләгән кешеләр белән ул ни өчен канәгать булмаска тиеш иде? Ә бит аңа якынлашу - нәкъ менә аның сөюен һәм канәгатьлеген алуда тора да бит инде.

**Сигезенче дәлил:** Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) камиллекләрен һәм кылган могҗизаларын белү – аңа булган ышануны ныгыта, Пәйгамбәрне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сөюбезне арттыра һәм көчәйтә. Кеше үзенең табигате белән матурлыкны, гүзәллекне сөя торган итеп яратылган.

Ә Пәйгамбәрнең әхлак сыйфатларыннан, камиллекләреннән, өстенлекләреннән дә камилрәк, матуррак һәм гүзәлрәк әхлак сыйфатлар, камиллекләр һәм өстенлекләр юк. Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) булган мәхәббәтне арттыру, аңа булган ышанычны камилләштерү - Шәригать белән таләп ителә, ә аңа ярдәм иткән барысы да, шулай ук, - Шәригать таләпләре исәбендә.

**Тугызынчы дәлил:** Пәйгамбәрне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) олылауның Шәригатьтә кануни нигезе бар. Ә затлы бу туган көн уңаеннан шатлык белдерү, сыйлар әзерләп, мәҗлесләр оештыру, Аллаһы Тәгаләне зикер итәр өчен кешеләрне җыю, ярлы һәм мохтаҗларга ихтирам һәм ярдәм күрсәтү – Аллаһ Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аша безне Үзенең чын туры диненә алып чыгуы, Мөхәммәд Пәйгамбәрне (аңа Аллаһның рәхмәте һәм иң яхшы сәламе булсын!) безгә җибәреп, безгә зур рәхмәт күрсәткәне өчен, Аллаһы Тәгаләгә бик зур олылавыбызны, шатлыгыбызны, рәхмәтебезне белдерү ул.

**Унынчы дәлил:** Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) җомга көненең үзенчәлекләре һәм фазыйләтләре турында шулай дигән:

وَفِيهِ خُلِقَ آدَمُ

*“Бу көнне Адәм (аңа Аллаһның сәламе булсын!) яратылган”.*

Моннан шундый нәтиҗә чыгарырга була: әгәр

дә бу турыда анык билгеле булса, Аллаһ пәйгамбәрләренең (аларга Аллаһның сәламе булсын!) кайсысы да булса дөньяга килгән көнне Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) зурлаган, олылаган. Ә рәсүлләрнең иң лаеклысы, пәйгамбәрләрнең иң яхшысы – Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) дөньяга килгән көнне, ул вакытта, нинди дәрәҗәдә олыларга кирәк соң?

Мондый олылау бу көнгә генә кагылып калмый, ул, алда искә алынган шул җомга көне кебек, алар кабатланган вакытта, шуңа охшашлы истәлекле башка көннәргә дә, шул исәптән мәүлид көненә дә кагыла. Без мондый көннәрдә пәйгамбәрлекләрнең үзенчәлек һәм өстенлекләрен чагылдырып, элек булып үткән, бар кешелек дөньясы һәм ахирәт өчен әһәмиятле, күренекле вакыйгаларны искә төшереп, Аллаһы Тәгаләгә шул вакыйгалар өчен рәхмәтебезне белдерәбез. Шуңа охшаш рәвештә, Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган урынын олылау да бер вакыйгадан башланып киткән. Җәбрәил (аңа Аллаһның сәламе булсын!) Мөхәммәд Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Вифлеемда *(Байтал-Ляхм)* ике рәкагәть намаз укырга кушкан һәм аннан шулай дип сораган: “Син үзеңнең кайда намаз укыганыңны беләсеңме?”. Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аңа: “Юк”, - дип җавап биргән. Җәбрәил дәвам иткән: “Син Вифлеемда, Гайсә (аңа Аллаһның сәламе булсын!) пәйгамбәрнең туган урынында намаз укыдың”, – дигән. Бу турыда Шаддад бине Гавасның, әл-Баззар, Әбү Ягла һәм әт-

Табарани тапшырган хәдисендә бәян ителә. Әл-Хафиз әл-Хайсамий “Мөҗмаг әз-зәваиди” китабында бу хәдисне сахих хәдис дип атый. Шул ук хәдисне әл-Хафиз бине Хәҗәр “Фәтху әл-Барий” китабында да китерә.

**Унберенче дәлил:** Мәүлид, ул – бар илләрнең дә дин галимнәре һәм мөселманнары хуплаган гамәл. Аны җир шарының һәр почмагында билгеләп үтәләр, аны билгеләп үтү Шәригать буенча да (бине Мәсгуд әйтеп калдырган хәдис буенча урнаштырылган кагыйдәдә) таләп ителә. Ул хәдистә шулай диелгән: *“Мөселманнар яхшы дип исәпләгән һәр нәрсә Аллаһ алдында да яхшы, мөселманнар начар, лаексыз дип исәпләгән әйберләр – Аллаһ каршында да начар, лаексыз”*. Бу хәдисне имам Әхмәд тапшырган.

**Уникенче дәлил:** Мәүлид вакытында мөселманнар бер урынга җыелалар, Аллаһны зикер итәләр, бер-берләренә бүләкләр тараталар, Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) салават әйтәләр, ә болар барысы да – сөннәт гамәлләр. Бу гамәлләр барысы да Шәригать тарафыннан бездән таләп ителәләр, алар мактауга лаек гамәлләр. Бу фикернең файдасына сахих риваятьләр сөйли, алар безне шундый гамәлләр кылырга өндиләр.

**Унөченче дәлил:** Аллаһы Тәгалә, шулай ук, тагын шул сүзләрне әйткән:

وَكُـــلاًّ نَّقُصُّ عَلَيْكَ مِنْ أَنبَاءِ الرُّسُلِ مَا نُثَبِّتُ بِهِ فُؤَادَكَ

(Мәгънәсе): ***“Ий пәйгамбәр! Рәсүлләрем турындагы хикәяләр белән Мин синең күңелеңне***

Әссаләәтү үәс-сәляямү, галәйкә,
йә, Хайри Халькыйлләәһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-Әәхыйриин.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Рахмәтәл лиль-гәәләмиин.

* * *

Бер Хода юктан бар итте дөньяны,
Мостафаның нуры берлән нурлады.
Һәм бар итте элек шул нурыни ул,
Һәм дә барлыкның зурысы булды ул.
Ошбу нурдан күк йөзенең сафлыгы,
Ошбу нурдан җир йөзенең барлыгы.
Гарше Көрси ошбу нурдан бар була,
Дөньяның күрке шушы нурдан гына.
Булмаса ул булмас иде бер ни дә,
Һәм яратмас иде җирне, күкне ди.
Булмаса ул булмас иде бер адәм,
Һәм яратмас иде дөньяны тәмам.
Яратылды аның өчен һәммәсе.
Аның өчен бар итте бәндәсени.
Хак яратды хәзрәти Адәмне ул.
Һәм балкыды маңгаендан ошбу нур.
Шул сәбәпле мәртәбәле булды ул.
Ошбу нур хәлифә итте һәм аны,
Һәм фәрештәләргә юлдаш итте аны.
Сәҗдә кыйлды һәр фәрештә шул сәбәп,
Күккә ашты хөрмәти һәм шул сәгать.
Соңра бу хәл бар баласына күчеп,
Килде Габдуллага хәтле ул үсеп.
Һәм аның да маңлаенда чыкты нур,
Нәкъ кояш кебек күк ялтырады ошбу нур.

Вакты җиткәч күчте нур Габдулладан,
Балкыды ул хәзрәти Әминәдән.
Йөкле булды ул хәбибнең анасы,
Җитте туар вакты энҗү данәсе.
Әгәр шәфәгать кирәк исә эзләгез,
Ул Расүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

## *Мәүлид мөнәҗәтләре*

Рәсүлүлла намазда ул
Башындадыр аның таҗы
Өммәти, өммәти диеп
Агадыр күзендин яше.

Рәсүлүлла раузасында
Зикер әйтеп сайрый кошлар
Шул кошлардан гыйбрәт алып
Салаватлар әйтик дуслар.

Салаватларга кушылыгыз
Салаватларын белгәннәр
Җәннәт ишеген ача алмаслар
Салаватлар әйтмәгәннәр.

## *Салават*

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Расүүләллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Нәбийәллааһ.

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
    йә, Хәбиибәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәляямү, галәйкә,
    йә, Хайри Халькыйлләәһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
    йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-Әәхыйрииин.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
    йә, Рахмәтәл лиль-гәәләмиин.

* * *

Әминә хатын - Мөхәммәд анасы,
Ул сәдәфтән туды энҗе данәсе.
Ул – Мөхәммәд, дөньяга хөрмәт итәр,
Вакыт җитте килмәккә хәйрел – бәшәр.
*(Кешелекнең иң хәерлесе)*
Инде аның килүе булды анык,
Күп галәмәт пәйда булды алдан ук.
Ул рабигыль – әүвәл аенда иде,
Уникенче киче, дүшәмбе иде.
"Күрдем" – диде, ул Мөхәммәд анасы,
"Бер гаҗәп нур, нәкъ кояшның яктысы!
Ялт итеп чыкты өемнән шул заман,
Күкләргә тик нур белән тулды җиһан.
Һәмдә һавада түшәлде бер түшәк,
Аты сөндүс, түшәгән аны мәләк.
Өч әләм тагын куйдылар өч җиргә,
Аралары бик ерак бер беренә.
Бере мәшрикъ, бере мәгърибтә аның,
Бересе нәкъ уртасында Кәгъбәнең.
Белдем аннан ул мөбәрәкнең нурын,
Заһир булды килмәсеннән әүвәллин.
Иңде күктән күп фәрештә сафи саф,
Кәгъбә кебек кылдылар өем тавааф.

Кинәттән өч хур кызы пәйдә булды,
Кайдан кергәннәрен, аңлап булмады.
Өчесе дә яныма утырдылар,
“Мостафа килә!” – диеп гәп кордылар.
Диделәр: “Углың кебек хөрмәтлене,
Ул Ходай һичбер анага бирмәде!
Бик олугъ дәүләт иясе буласың,
Холкы күркәм бер угыл тудырасың!
Бу угыл гыйлме ләдүн солтаныдыр, *(Аллаһыдан бирелгән гыйлем иясе)*
Бу угыл тәүхиде гыйрфан кянидер!”
Сыйфатын шул рәвешчә аңлаттылар,
Ул мөбәрәк нур белән шатландырдылар!”
Диде Әминә: “Вакыт җитте тәмам,
Килә инде дөньяга хәйрел – әнәм. *(кешеләрнең иң хәерлесе)*
Эсселектән сусадым гаять катый,
Шул вакыт эчерделәр бер ширбәти.
Ап - ак иде, кардан да салкын иде,
Бу кеби тәм дөньяда һич юк иде.
Эчтем аны, барча эгъзам булды нур,
Эчемә һәм тышыма да тулды нур.
Килде бер аккош канат илә очып,
Аркамнан ул сыйпады, монда төшеп.
Тугъды шул сәгатьтә ул солтани дин,
Нурга тулды барлык сәмәват – зәмин. *(күкләр – җир)*
Әгәр шәфәгать кирәк исә эзләгез,
Ул Расүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

## *Мәүлид мөнәҗәтләре*

Рәсүлүлла намазда ул
Башындадыр аның тажы
Өммәти, өммәти диеп
Агадыр күзендин яше.

Рәсүлүлла раузасында
Зикер әйтеп сайрый кошлар
Шул кошлардан гыйбрәт алып
Салаватлар әйтик дуслар.

Салаватларга кушылыгыз
Салаватларын белгәннәр
Җәннәт ишеген ача алмаслар
Салаватлар әйтмәгәннәр.

## *Салават*

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
 йә, Расүүләллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
 йә, Нәбийәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
 йә, Хәбиибәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәляямү, галәйкә,
 йә, Хайри Халькыйлләәһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
 йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-Әәхыйриин.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
 йә, Рахмәтәл лиль-гәәләмиин.

www.jarul-kutub.com

# Мәхәле кыям (аягүрә басып)

Расүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренең тууы зикер ителгән вакытта аягүрә торып, салават шәриф уку галимнәр күзлегеннән бик күркәм эш итеп кабул ителгәнгә күрә, гарәп голямәләре, бигрәк тә, Хәрәмәйни – шәрифәйни (Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендәге Хәрәм мәчетләре) голямәләре бу урында аягүрә басып, салават шәрифне укырлар. Түбәндәге бәетләрне аягүрә торып басып уку тиешле була. Чөнки бөек галимнәрнең сүзләре буенча Расүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәллам әфәндебезнең туу вакыты искә алынып сөйләнелсә, шул зикер ителгән мәҗлескә аның мөбәрәк рух шәрифләре пәйда була диеләә!

Яратылмыш барча мәхлүк булды шат,
Кайгылар китте галәмнән, калды саф.
Бар тереклек галәмнәргә кылып сәда, *(аваз салып)*
Барсы берләшеп диделәр: “Мәрхабә!”
Мәрхәбә, ий гали солтан, мәрхәбә! *(бөек солтан)*
Мәрхәбә, ий кяни солтан, мәрхәбә!*(инанганнарның солтаны)*
Мәрхәбә, ий куррәтуль-гәйни хәлил! *(күз шатлыгы булган дус)*
Мәрхәбә, ий хасси мәхбүби Җәлил! *(Аллаһының сөеклесе)*
Мәрхәбә, ий җөмләнең матлубы син! *(барчасының теләге)*
Мәрхәбә,ий Халикъның мәхбүбе син!*(Аллаһының сөеклесе)*
Мәрхәбә, ий җани җанан, мәрхәбә!

Мәрхәбә, ий дәрдә дәрман, мәрхәбә! *(хастага шифа)*
Мәрхәбә, ий гасый өммәт мәлҗаи! *(гөнаһлыларны сыендыручы)*
Мәрхәбә, ий чарасызлар әшфагый! *(чарасызларның яклаучысы)*
Мәрхәбә, ий рахмәтәл лил галәмин! *(галәмнәрнең рахмәте)*
Мәрхәбә син, ий шәфигуль музнибин! *(гөнаһлыларның шәфәгатьчесе)*
Ий җәмали көн, йөзе бәдре мөнир! *(тулган ай йөзле, көн кебек матур булган)*
Ий каму дүшәнләрә син дәстәгир! *(авырлыкка төшкән һәммәсенә ярдәмче)*
Ий күңелләр дәрдәнең дәрманы син! *(күңел хасталарының дәвасы)*
Ий яратылмышларның солтаны син! *(дөнья мәхлүкләренең солтаны)*
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

## *Мәүлид мөнәҗәтләре*

Рәсүлүлла намазда ул
Башындадыр аның тажы
Өммәти, өммәти диеп
Агадыр күзендин яше.

Рәсүлүлла раузасында
Зикер әйтеп сайрый кошлар
Шул кошлардан гыйбрәт алып
Салаватлар әйтик дуслар.

www.darul-kutub.com

Салаватларга кушылыгыз
Салаватларын белгәннәр
Җәннәт ишеген ача алмаслар
Салаватлар әйтмәгәннәр.

## *Салават*

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Расүүләллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Нәбийәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Хәбиибәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәляямү, галәйкә,
йә, Хайри Халькыйлләәһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-Әәхыйриин.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Рахмәтәл лиль-гәәләмиин.

* * *

Мәккә халкының олугълары рәвах,
Кылдылар Кәгъбәне бер кич таваф.
Күрделәр Кәгъбәне, сәҗдә кылды ул,
Төшмәде бер ташы, кире торды шул.
Кәгъбәнең почмаклары бирде сәлам,
Диделәр: "Кем, тугъды ул хәйрел – әнам!"
Кәгъбәтулладан ишетелде сәда, *(аваз)*
Диде: "Тугъды бу кичә нур әл һуда!"*(һидаять нуры)*
Яланаяк, башы ачык, сафи саф,
Итәчәк өммәтләре мине таваф.
Чистартып поттан, кяфердән ул Расүл,
Коткарачак мине мөшрикләрдән ул!"



www.darulkutub.com

Фәхре галәм җитте кырык яшенә,
Пәйгамбәрлек таҗын киде башына.
Иңде Коръән Аллаһтан аять – аять,
Пәйда булды ничә төрле могъҗизәт.
Әүвәле ул кем, мөбәрәк тәненең,
Күләгәсе төшмәде җиргә аның.
Чөнки аның нур иде бар гәүдәсе,
Нурның булмас һичкайчан күләгәсе.
Аның мөбәрәк баш өстендә һәрзаман,
Күләгәләп бер болыт йөрде һаман.
Мөхәммәд туган көненең кичәси,
Тулды нур белән бөтен дөнья дәхи. *(тагын)*
Шәүләсе итте аның Шамда зуһур,
Әһле Мәккә күрделәр, кем, юк кусур. *(кимчелек)*
Сүнде фарси магъбүденең утлары,
Чыкты ташып Бохәйраның сулары.
Күп гаҗәеп могъҗизалар күрделәр,
Тугъдыгы көн икәнлеген белделәр.
Фәхре галәм тууынча барча җан,
"Бик зур шатлык безгә, - диделәр – һаман!"
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн–нүзүл!

## *Мәүлид мөнәҗәтләре*

Рәсүлүлла намазда ул
Башындадыр аның таҗы
Өммәти, өммәти диеп
Агадыр күзендин яше.

Рәсүлүлла раузасында
Зикер әйтеп сайрый кошлар
Шул кошлардан гыйбрәт алып
Салаватлар әйтик дуслар.

Салаватларга кушылыгыз
Салаватларын белгәннәр
Җәннәт ишеген ача алмаслар
Салаватлар әйтмәгәннәр.

## *Салават*

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Расүүләллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Нәбийәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Хәбиибәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәляямү, галәйкә,
йә, Хайри Халькыйлләәһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-Әәхыйрииин.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Рахмәтәл лиль-гәәләмиин.

## *Мәүлид мөнәҗәтләре*

Рәсүлүллаһ бораклары
Көмештәндер тояклары
Ихлас белән гамәл кыйлың
Без бу дөнья кунаклары.

Ходайга гашыйк булганнар
Зикердә булганнар алар
Шулар белән булыр өчен
Зикер әйтик мөселманнар!

www.garuykutub.com

Шәфәгатен өмет итеп
Салаватлар әйтсәк иде
Бер Ходаем кабул итеп
Морадларга җитсәк иде.

Ходайның дусты — Пәйгамбәр
Туган ай бу мөселманнар
Бу ай — бәйрәм һәркөн шатлык
Мөкатдәс бик шәриф ай бу.

Туды Мәккә шәһәрендә
Рабигуль әүүәл аенда
Дүшәмбе көн, уникенче сәхәр
Вакыты иде таң алдында.

Рәсүлүллаһ туган чакта
Сөннәтле күзе сөрмәле
Туу белән сәҗдә кылды
Яуды Аллага рәхмәте.

Аңар өммәт булу белән
Безне хөрмәтләде
Вә көн төн хайри өммәт дип
Хәбәр бирде үзе.

Рәсүлүлла намазда ул
Башындадыр аның таҗы
Өммәти, өммәти диеп
Агадыр күзендин яше.

Рәсүлүлла раузасында
Зикер әйтеп сайрый кошлар

www.darul-kutub.com

Шул кошлардан гыйбрәт алып
Салаватлар әйтик дуслар.

Салаватларга кушылыгыз
Салаватларын белгәннәр
Җәннәт ишеген ача алмаслар
Салаватлар әйтмәгәннәр.

***Салават***

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Расүүләллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Хәбиибәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-Әәхыйриин.
Үә саллүү галәә җәмиигыль-Әнбиәә-и
үәль-мурсәлиин.
Үәльхәмдү лилләәһи раббиль-гәәләмииин.

***Мәүлид укыганда һәркем үзенә охшаган бер салаватны да әйтеп укый ала.***

# Тәмамлау догасы

Йә, Рәхмәтле Раббым, укылган Коръән аятьләребезнең, салаватларыбызның хата-кимчелекләрен гафу итеп, Үзеңнең киң рәхмәтең белән кабул кылсаң иде.

Ошбу Коръән аятьләреннән, салаватларыбыздан хасил булган әҗер вә савапларны фани дөньядан мәңгелек ахирәткә күчкән иң камил кеше, бөтен галәмнәргә рәхмәт

буларак җибәрелгән, барлык пәйгамбәрләрнең имамы булган сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлламнең рухына, атабыз Адәм галәйһиссәләм һәм анабыз Һавадан алып бүгенге көнгә кадәр килгән бөтен пәйгамбәрләрнең, әүлияләрнең, галимнәрнең рухларына ирештерсәң иде. Шулай ук безнең догаларыбызга мохтаҗ булган газиз әти-әниләребезнең, әби-бабаларыбызның, дәү әти-дәү әниләребезнең, кыз һәм ир туганнарыбызның, барча мөэмин-мөселман кабер әһелләребезнең, мәрхүм-мәрхүмәләребезнең рухларына ирештереп, аларның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен гафу итеп, рухларын шатландырсаң иде.

Йә, Кодрәтле Раббым, аларның каберләрен нурландырып, хисапларын җиңеләйтсәң иде. Аларга Синең сөекле бәндәләреңнән, җәннәт әһелләреннән булырга насыйп итсәң иде.

Йә, Рәхим-шәфкатьле Раббым, укылган Коръән аятьләребез, әйтелгән салаватларыбыз, игелекле гамәлләребез хөрмәтенә, белеп һәм белмичә кылган гөнаһларыбызны, хата-кимчелекләребезне, ялгышларыбызны Үзеңнең киң рәхмәтең белән гафу итсәң иде.

Хосусан, сөекле Пәйгамбәребезнең туган вакытын бәян иткән касыйдәсен укучыларга һәм тыңлаучырга Пәйгамбәребез шәфәгатен насыйп итсәң иде! Шулай ук барча дин кардәшләребезгә һәр урында һәм һәрвакыт Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлламнең Сөннәтен тотарга һәм Аңа ияреп яшәргә насыйп итсәң иде.

Киләчәктә дә шушы мәҗлес кебек хәерле мәҗлесләрне күрергә һәм үткәрергә насыйп итсәң иде!

Йә, Раббым, йөрәкләребезгә көчле иман, җаннарыбызга тынычлык, тәннәребезгә исәнлек-саулык биреп, һәрбарчабызга хәерле һәм бәракәтле гомерләр насыйп итсәң иде. Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Синең кушканнарыңны ихлас күңелдән үтәп, тыйган гамәлләреңнән тыелып, иксез-чиксез рәхмәтеңә һәм ризалыгыңа ирешергә, ике дөньяда да бәхетле бәндәләреңнән булырга насыйп итсәң иде.

Һәркайсыбызны хәвеф-хәтәрләрдән, сугышлардан, ачлык хәсрәтеннән, сихерләрдән, табигать гарасатларыннан Үзең сакласаң иде. Ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек насыйп итсәң иде.

Йә, Рәхмәтле Раббым, балаларыбызга, оныкларыбызга күркәм тәрбия биреп, алар өчен сөенеп, шатланып яшәргә, аларның игелеген, миһербанлыгын күрергә насыйп итсәң иде.

Йә Раббым, һәркайсыбызга бу дөньядан тулы иман, кальби сәлим белән китәргә, соңгы сулышларыбызда да: “Ләә иләәһә иллә ллааһу Мөхәммәдүррасүлүллаһ”, - дип әйтергә насыйп итсәң иде. Кыямәт көнендә сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең шәфәгатенә ирешеп, җәннәтләреңә керергә, Синең дидарыңны күрергә насыйп итсәң иде.

Раббәнәә әәтинәә фиддүнйәә хәсәнәтәү үә фил әәхыйрати хәсәнәтәү үә кыйнәә гәзәәбән-нәәәр.

Вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлилләһ үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.

www.darulkutub.com

## Эчтәлек

Мәүлид мөбарәк булсын! .......................................5
Мәүлид бәйрәмен үткәрүнең дөреслегенә
Дәлилләр ..........................................................7
Мәүлидүн-нәби бәйрәме хакында
бер-ике сүз. ...................................................... 25
Пәйгамбәребез Мөхәммәд
галәйһиссәләм – иң камил кеше. .........................27
Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә
карата булган әдәп..............................................32
Мәүлид кичәсенең фәзыйләтләре.........................35
Мәүлидне үткәрү тәртибе. ...................................36
Мәүлидтә укыла торган аять-сүрәләр.................36
"Әл-Ихлас" сүрәсе. .............................................36
"Әл-Фәләк" сүрәсе. .............................................37
"Ән-Нәс" сүрәсе. ..................................................38
"Әл-Фәтихә" сүрәсе. ............................................39
"Әхзәб" сүрәсе, 40-48нче аятьләр. .......................40
Саләүәәтүл макбүүлә. ..........................................41
Рәсүл әкрамның нәсәл-нәсабы шәрифе. .............44
"Мәүлидүн-нәби" касыйдәсе. ...............................45
Мәхәле кыям.........................................................54
Тәмамлау догасы...................................................60

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

***(ихтыяр көчеңне) ныгытмак буламын. Һәр нәрсәне сиңа аңлатам. Аларда синең өчен хакыйкать, мөэминнәр өчен кисәтү вәгазе бар”*** (11-че сүрә, “Һуд”, 120 аять).

Моннан Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәргә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) башка пәйгамбәрләр (аларга Аллаһның сәламе булсын!) тарихындагы вакыйгаларны аның мөбәрәк күңелендәге иманын ныгыту һәм камилләштерү өчен сөйләве ачыклана.

Һәм безнең барыбызның да, пәйгамбәрләрнең иң яхшысының тормышы һәм тормыш эшчәнлеге турындагы хикәятләрне тыңлап, күңелләребездәге иманны ныгыту һәм камилләштерүдә аннан күпкә мохтаҗрак икәнебезгә бернинди дә шик юк. Чынлап та, безнең моңа ихтыяҗыбыз бик зур.

**Ундүртенче дәлил:** Бездән алда яшәгән тәкъва мөселманнар *(сәләфсалихун)* эшләмәгәннәрнең, Исламның беренче чорында булмаганнарның барысы да тыелган гамәл дә, кире кагылырга тиешле гамәл дә, начар бидгать тә түгел. Ләкин, һәр яңалыкны, һәр яңа кертелгәнне Шәригать дәлилләре белән тикшереп чыгарга кирәк. Анда дин өчен яхшылык *(мәсләхәт)* бармы, ул *вәҗиб* гамәлме, анда *хәрам* (тыелган гамәл) өлеш юкмы, шуның нәтиҗәсендә ул хәрам гамәл түгелме, әллә инде анда хупланмаган өлеш бармы һәм шуның нәтиҗәсендә ул хупланмаган *(мәкруһ)* гамәлме, яки ул рөхсәт ителгән өлешләрдән генә торамы һәм рөхсәт ителгән *(мөбах)* гамәлме, яки анда хупланган өлешләр генә һәм дә ул хупланган *(мандуб)* гамәлме. Ә кулланылган чаралар өчен, максатлар

өчен кулланыла торган шул ук Шәригать карарлары кулланыла.

Дин галимнәре яңалык кертүләрне биш төргә бүлгәннәр.

1. Зарури яңалык кертүләр. Мәсәлән, хак юлдан язган агымнарның фикерләрен кире кагу һәм аларның вәкилләренә каршы чыгыш ясау; Изге Коръән һәм Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хәдисләрен укыган вакытта ялгышмас өчен, гарәп теленең грамматикасын өйрәнү.

2. Хуплана торган яңалык кертүләр. Мәсәлән, ятимнәр йортлары, мәктәпләр төзүләр, намазга чакырып, манаралардан *азан* әйтү һәм башка игелекле эшләр эшләү. Алар Исламның башлангыч чорында булмаганнар.

3. Хупланылмаган яңалык кертүләр: алар мәчетләрне һәм Изге Коръән битләрен орнаментлар белән артык бизәкләү кебек гамәлләр.

4. Рөхсәт ителгән яңалык кертүләр. Мәсәлән, онны иләр өчен иләктән файдалану, төрле яңа ризык һәм эчемлекләр куллану һ.б.

5. Тыелган яңалык кертүләр. Болар – Сөннәткә каршы килгән, Шәригать дәлилләренә туры килмәгән, Шәригатькә файда, яхшылык китермәгән гамәлләр.

**Унбишенче дәлил:** Һәрбер яңалык кертү дә тыелган була алмый. Әгәр бу шулай булса, Әбү Бәкер, Гомәр һәм Зәедләрнең (Аллаһ алардан риза булсын!) Изге Коръән текстларын җыеп туплавы, аннан соң бу текстларны, Коръәнне яттан укучылар (Аллаһ алардан риза булсын!) вафатыннан соң

югалтмас өчен, кәгазь битләрендә теркәүләре, шулай ук, тыелган гамәл булып исәпләнгән булыр иде. Шулай ук, Гомәрнең (Аллаһ аңардан риза булсын!), *"Нинди гүзәл яңалык кертү бу!",* - дип әйтеп, кешеләрне Рамазан аенда тәравих намазы уку өчен бергә җыюы да, шулай ук, тыелган гамәл булып исәпләнер иде. Гыйлемнең төрле файдалы өлкәләре буенча хезмәтләр дә тыелган булырлар иде, алар утлы корал, артиллерия, танклар, авиация, су асты көймәләре һәм диңгез флоты белән сугышкан вакытта, безгә каферләргә каршы ук һәм җәяләр белән сугышырга туры килер иде.

Манаралардан азан әйтү дә, ятимнәр йортлары, мәктәпләр, шифаханәләр, ашыгыч ярдәм, төрмәләр өчен биналар төзү дә тыелган булыр иде. Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) шундый бер хәдисе бар:

كُلُّ بِدْعَةٌ ضَلاَلَة

*"Һәрбер бидгать – юлдан язудыр".*

Дин галимнәре аны начар яңалык кертү дип исәпләгәннәр. Ләкин андый чикләү Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) өлкән сәхәбәләре һәм аларның дәвамчылары *(табигыйннар)* керткән гамәлләргә рөхсәт биргән. Ләкин, ул гамәлләр Аллаһның Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) вакытында булмаганнар. Без үзебез дә бүгенге көндә бездән элек яшәгән тәкъва мөселманнарда булмаган күп яңалык кертүләр кулланабыз. Мәсәлән, тәравихтан соң, бер имам артыннан тәхәҗҗуд намазы укыр өчен, төн ахырында кешеләрне җыю, анда Коръән укуны

тәмам итү, Коръән укуны тәмамлаган вакытта Аллаһка ялвару, егерме җиденче кичәдә тәхәҗҗүд намазында имамның вәгазь укуы, дингә чакыручының шундый сүзләр белән мөрәҗәгать итүе: “Төнге намазга басыгыз, Аллаһ безгә моның савабын бирсен!”. Боларның берсен дә Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) дә, бездән алда яшәгән тәкъва мөселманнар да башкармаганнар. Ә мондый очракларда безнең бу гамәлләргә тәкълид итүебез тыелган гамәл булып санала аламы?

**Уналтынчы дәлил:** Мәүлидне билгеләп үтү, гәрчә ул Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) чорында булмаса да, яңалык кертү булып тора, тик яхшы яңалык кертү. Чөнки, ул Шәригать дәлилләренә һәм абсолют кагыйдәләргә туры килә. Мәүлид аның состав өлешләре буенча түгел, ә аны үткәрү формасы белән, ягъни, аны үткәрү өчен кешеләрне махсус җыю буенча, - яңалык кертү. Чөнки мәүлидне билгеләп үткән вакытта булганнарның барысы да, Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) вакытында булганнар. Бу турыда мәүлид файдасына без китергән уникенче дәлилдә бар.

**Унҗиденче дәлил:** кешеләрне җыю кебек, Исламның башлангыч чорында булмаган, ләкин аның структур өлешләре ул вакытларда булган һәр гамәл, Шәригать буенча зарур гамәл булып исәпләнә, чөнки ул законлы өлешләрдән тора. Ә законлы өлешләрдән торган һәр әйбер үзе дә законлы була. Һәм бу беркем өчен дә сер түгел.

**Унсигезенче дәлил:** Имам әш-Шәфигый

(Аллаһ аңарга рәхимле булсын!) шулай дигән: *“Барлык яңалык кертүләр дә ике төргә бүленә. Аларның беренчесе - Коръәнгә, Сөннәткә, иҗмагка*[4] *яки асарга*[5] *каршы килүче яңалык кертүләр. Андый яңалык кертүләр юлдан язу булып торалар. Икенчеләре – яхшы яңалык кертүләр, алар алда саналганнарның берсенә дә каршы килмиләр. Андый яңалык кертүләр рөхсәт ителәләр һәм мактауга лаеклар”*. Имам әл-Иззу бине Габд әс-Сәлам, ән-Навави, бине Асирлар да яңалык кертүләрне без алда күрсәткән төрләргә бүленәләр дип язалар.

**Унтугызынчы дәлил:** Шәригать дәлилләренә туры килгән һәр игелекле гамәл, аны кулланышка кертү – Шәригатькә каршы килүне максат итеп куймый, әгәр дә анда тыелганнар булмаса, ул дингә кабул ителә.

Бездән алда яшәгән тәкъва мөселманнар *(сәләфсалихун)* боларны башкармаганнар, – дигән фанатиклар фикере, гомумән дәлил була алмый, киресенчә, бу – дәлилләрнең булмавын аңлата. Һәм дә бу диннең нигезләрен *(үсүл)* өйрәнү белән шөгыльләнгән кеше өчен, гомумән сер түгел. Безгә кануннар урнаштыручы - Пәйгамбәр (аңа

---

[4] *Иҗмаг* –мөселман дин галимнәренең бертавыштан уртак фикергә килүләре.

[5] *Асар* – Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сәхәбәсе чыгарган дини фәтва яки Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аның аша тапшырылган сүзләре яки гамәлләре.

Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!), аны башкарган кешегә савап вәгъдә иткән, чөнки аның хәдисендә шулай диелгән: *“Исламга яхшы традиция керткән кеше, аның өчен савабын алыр, һәм аның үрнәгенә ияргән кешеләрнең савапларын да. Бу вакытта аның артыннан барган кешеләрнең savaплары кимемәс”*. Мөслим тапшырган хәдистә шулай диелгән.

**Егерменче дәлил:** Пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) мәүлиден олылау – Аллаһ Рәсүле (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) турындагы хатирәләрне торгызу булып тора, ул Исламда рөхсәт ителгән һәм законлы гамәл. Хаҗ кылырга барган вакыттагы күп йолаларны башкару да, истәлекле хатирәләрне, вакыйгаларны хәтердә яңарту, мактаулы тарихи урыннарга сәяхәт кылу булуын барыбыз да күрәбез бит. Мәсәлән, Сафа һәм Мәрвә[6] таулары арасыннан үтү, ташлар ыргыту, Мина[7] үзәнендә корбан чалу -

---

[6] *Сафа һәм Мәрвә* – Мәккәдәге таулар. Анда, я бер тауга, я икенчесенә йөгереп менеп, Исмәгыйль (аңа Аллаһның сәламе булсын!) пәйгамбәрнең әнисе Хәҗәр кечкенә баласы өчен су эзләп йөргән. Ул җиде тапкыр шулай йөгереп үткән. Шуннан соң, Исмәгыйль (аңа Аллаһның сәламе булсын!) пәйгамбәр янында изге Зәм-зәм чишмәсе бәреп чыккан. Һәм бу җиде тапкыр йөрүне Аллаһы Тәгалә соңыннан хаҗ кылу йолаларының берсе иткән.

[7] *Мина* – Мәккәдән ерак түгел бер урын. Анда Ибраһим (аңа Аллаһның сәламе булсын!) пәйгамбәр, Раббыбыз кушуы буенча үзенең яраткан улы Исмәгыйль (аңа Аллаһның сәламе булсын!) пәйгамбәрне корбан

болар барысы да, бик күптән булып үткән вакыйгалар белән бәйләләр. Мөселманнар, хәзер дә элекке замандагы кебек итеп аларны башкарып, алар турындагы хәтерне яңарталар. Ә Аллаһы Тәгаләнең Ибраһим һәм Исмәгыйль (аларга Аллаһның сәламе булсын!) пәйгамбәрләр вакыйгасы турында сөйләгәндә әйткән сүзләре моңа, шулай ук, дәлил булып тора:

وَأَذِّن فِي النَّاسِ بِالْحَجِّ

(Мәгънәсе): ***“Мөселман булган җәмәгатькә хаҗ гамәлләрен кылуны игълан ит”*** (22-нче сүрә, ”Хаҗ (Хаж)”, 27 аять).

وَأَرِنَا مَنَاسِكَنَا

(Мәгънәсе): ***“Безгә гыйбадәт урыннарын һәм ысулларын өйрәт”*** (2-че сүрә, ”Бакара (Сыер)”, 128 аять).

**Егерме беренче дәлил:** Мәүлиднең законлы икәне файдасына без алда китергән бар дәлилләр дә, мәүлиднең тыелган һәм аларны кире кагарга кирәк булган аспектлардан азат булган гамәл икәнлеге турында сөйлиләр. Әгәр дә мәүлидне

---

итәргә әзерләнгән булган. Аларның бу сынауны лаеклы үтүләрен күргәч, Җәбрәил (аңа Аллаһның сәламе булсын!), Аллаһ Тәгаләнең рөхсәте белән, Җәннәттән бер сарыкны аңа китереп биргән. Ибраһим (аңа Аллаһның сәламе булсын!) пәйгамбәр үзенең улы урынына шул сарыкны корбанга китергән.

үткәргән вакытта ирләр белән хатын-кызларның бергә җыелуы, гөнаһлар кылу, артыгын исраф итү кебек, мәүлид Хуҗасы канәгать булмаслык, кире кагарга тиешле гамәлләр була икән, мондый мәүлиднең, әлбәттә, тыелган һәм хупланмаган гамәл булуында бернинди дә шик юк. Ләкин, бу вакытта тыю аерым бер тискәре очракларга гына кагыла, ә мәүлиднең үзенең асылына түгел. Һәм дә бу, бу турыда фикер йөрткән кеше өчен, сер була алмый.

***Бөек ислам галиме, дүрт мәзхәб белгече, сәед (Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең нәселеннән булган), Мәккәдә һәм Мәдинәдә иң зур хөрмәткә лаек булган Шәех Мөхәммәд ибне Галәви әл-Мәлики (1946-2004***

www.darul-kutub

# Мәүлидүн-нәби бәйрәме хакында бер-ике сүз

Элеккеге заманнарда Пәйгамбәребез Мөхәммәд Расүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәллам хәзрәтләренең туган көнен аерым - ачык билгеләп бәйрәм итү һәм шул көндә фәкыйрь – мескеннәрне ашлар ашатып, аларны сәдакалар биреп шатландыру, Расүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлламнең тууы, үсүе хакында гарәп яки төрки телләрдә бәян ителгән касыйдәләрне укылганы төгәл билгеле түгел.

Әмма һиҗри исәп белән алтынчы гасырда, Ирбиль падишаһы, Мәлик Мозаффар Әбу Сәгыйт Күкбүре бине Гали бине Биктәгин[8], Мөхәммәд Расүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлламне ихлас күңеленнән яратканга һәм үзе дә бик юмарт кеше булганга күрә, шушы "Мәүлид - шәриф касыйдәсе"н укуны һәм зур табыннар – ашлар әзерләп, халыкны җыеп ашатуны, шунда күп изгелек кылып, сәдакалар таратып, кешеләргә ярдәм итүләрне гадәткә кертә. Ул һәр ел саен "Мәүлид – шәриф" көнендә галимнәрне, мәшәехләрне һәм дә күп санлы фәкыйрьләрне җыеп зур аш мәҗлесе ясый. "Мәүлед – шәриф" касыйдәләрен укучыларга һәм голямә, мәшәехләргә яхшы, матур киемнәр бүләк итеп, якынча, өч йөз мең алтын микъдарында мал сарыф итә. Расүлүллаһ салләллаһү галәйһи вә сәлламне бик

---

[8] Әбү Сәгыйд Күкбүре бине Гали бине Биктәгин – Әрбил хөкемдары (1190–1232). Ул беренчеләрдән булып 1207 елны Мәүлидне бәйрәм буларак оештырган.

тә яратканга күрә, күңеле тулып, аның өммәтен, бихисап фәкыйрьләрне һәм гыйлем әһелләрен, бу “Мәүлид – шәриф” бәйрәме сылтавы белән, шулкадәр күп маллар сарыф итеп, шатландыра торган була.

Хафиз ибне Рәҗәп “Ләтаифүл – мәгариф” исемле китабында дүшәмбе көн ураза тотуның мөстәхәб булуы хакында хәдис шәриф бәян итеп, “Мәүлид шәриф бәйрәме” нә һәм анда, ачык рәвештә халыкка белдереп, шөкераналар кылырга кирәклегенә дәлилләр булганлыгын күрсәтә. Хәдисләр җыентыгы “Мөслим”дә, Әбү Котада, радыйаллаһү ганһүнең, риваять итүенчә, Расүлүллаһ салләлаһү галәйһи вә сәлламнән, аның дүшәмбе көн ни өчен ураза тотуы турында сорагач: “Зәликә йәүмүн вулидтү вә унзиләт галәйә фиһи ән нүбүвәтә!”- дип әйткән. Тәрҗемәсе: *“Бу көн мин туган һәм миңа пәйгамбәрлек иңдерелгән көн!”* – дип җавап бирә.

Димәк, бу Расүлүллаһ салләлаһү галәйһи вә сәллам үзенең туган көнен һәм пәйгамбәрлек килгән көнен аерым гыйбадәт белән хөрмәт итүе, шушы олы нигъмәт өчен (кешеләргә сөекле пәйгамбәрен җибәргәне өчен), мөселманнарның Аллаһы Тәгаләгә шөкерана кылырга тиешлеген күрсәтә. Шуңа күрә, ай хисабы буенча да аның туган көнен, шәригать кысаларыннан чыкмыйча, нинди рәвештә булса да хөрмәт итү нигезсез түгел, ә киресенчә дөрес икәнлеге исбатлана.

Телгә алынган Хафиз ибне Рәҗәпнең “Ләтаифүл – мәгариф” ендә, “Мөслим” дә Әбү Котада, радыйаллаһү ганһүнең риваяте буенча,

китерелгән хәдисләргә таянып исбат ителгәннән соң, шулай ук мөхәддис, фәкыйһ галимнәрне дә искә алып үтмичә булмас. Сүюти, Гаскалани вә Касталани хәзрәтләренең дә, бу мәсьәләдә хәдис шәрифләр китереп, Пәйгамбәребез галәйһис саләтү вәс сәламнең туган көнен ихтирам итүне, рөхсәтле һәм күркәм эш икәнлегенә фәтва биргәннәрен дә күрә алабыз. Боларны төгәл итеп белергә теләгән кешеләр, шәех Йосыф бине Исмәгыйль Нәбаһәнинең ”Хуҗҗәтуллаһи галәл галәмин фи мугъҗизәт сәйидиль мурсәлин” китабына мөрәҗәгать итә алалар!
Вәффәканә-ллаһу вә иййәкүм бимә фиһи ридаһү!
(Аллаһ безгә һәм сезгә Аның ризалыгын алырга ярдәм итсен!)

***Бу мәкалә Дамелла Галимҗан хәзрәт әл-Барудинең «әд-Дин вә-л-әдәб» журналыннан алынды***

# Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм – иң камил кеше

Безнең эраның алтынчы гасырында, бу дөньяга бөтен кешелек өчен үрнәк камил кеше җибәрелә – соңгы Пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәләм. Бөек Аллаһ изге Коръәндә җирдәге һәм Ахирәттәге тормыш бәхетле булсын өчен, барлык кешеләргә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә иярергә куша.

Мөхәммәд галәйһиссәләм, пәйгамбәрләр имамы буларак, барлык пәйгамбәрләрнең иң матур

сыйфатларын үзендә туплаган. Ул мул сулы елгалар койган диңгез кебек. Һәрбер кеше аның тормышын үзенә үрнәк итеп алырга мөмкин. Мөхәммәд галәйһиссәләм үзенең бер хәдисендә: *“Мин күркәм әхлакны камилләштерү өчен җибәрелдем”*, – дип әйткән (Әхмәд бин Хәнбәл, Муснад). Аллаһы Раббыбыз да Коръән Кәримендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмне мактап:

وَإِنَّكَ لَعَلى خُلُقٍ عَظِيمٍ

*“Хакыйкатьтә, син – югары әхлак иясе”, –* дигән. (“Каләм” сүрәсе, 4нче аять).

Ул игелекле, итагатьле, шәфкатьле, миһербанлы, сабыр, киң күңелле, юмарт, ышанычлы, тыйнак була. Бу сыйфатлар Пәйгамбәребез галәйһиссәләмдә иң камил дәрәҗәдә була. Коръәндә әйтелгән:

لَقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ
لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرً

*“Тәхкыйк, Аллаһ Расүлендә сезгә иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһтан савапны һәм ахирәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә, Аллаһны күп зекер итүче мөэминнәр өчен”* (“Әхзаб” сүрәсе, 21нче аять).

Аллаһ илчесе галәйһиссәләмнең әхлак чыганагы – Коръән булган. Шуңа күрә, Расүлебезнең холкы нинди иде соң? – дигән сорауга



www.darul-kutub.com

Гайшә анабыз (Аллаһ аннан разый булса иде): *“Аның холкы – Коръән иде”*, – дип җавап биргән. Ул Коръән Кәрим тыйган нәрсәгә ачуланып караган һәм Коръән Кәрим кушкан нәрсәдән канәгатьләнү тойган. Ул Аллаһка ошамаган гамәл кылучыларны хөкем иткән һәм шелтәләгән. Расүлебез галәйһиссәләм Аллаһ риза булмаган нәрсәләр өчен генә ачуланган.

Аллаһ расүле галәйһиссәләм югары дәрәҗәдә намуслы һәм ышанычлы, кешеләр белән мөнәсәбәттә йомшак һәм дустанә кеше булган. Ул әхлакый, саф фикер йөртергә яраткан. Аллаһ илчесе галәйһиссәләмгә тупаслык, әдәпсезлек һәм оятсызлык ят булган. Ул беркайчан да явызлыкка явызлык белән җавап бирмәгән, дошманнарын кичерә белгән. Әгәр кемдер аннан берәр нәрсә сораса, яки берәр нәрсә белән кызыксынса, Аллаһ илчесе галәйһиссәләм һәрвакыт йомшак һәм төпле итеп җавап биргән, тупас һәм ихтирамсыз бер сүз дә кулланмаган. Ул беркайчан да әңгәмәдәшен ярты сүздә бүлдермәгән. Әгәр берәрсенең сүзе чамадан чыкса, ул аны я кире каккан, я торып киткән.

Аллаһның расүле гәләйһиссәләм әйткән: *“Миңа тәрбияне Аллаһ үзе бирде, һәм бу тәрбия нинди күркәм булды”,* – дигән (Суюти “Җәмиг әс-сәгыйрь”). Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең күркәм яшәү рәвешен, әдәбен күреп бик сокланганнар. Әнәс бин Мәлик (Аллаһ аннан разый булса иде) дигән сәхабә әйткән: “Мин Аллаһның расүле гәләйһиссәләмгә ун ел хезмәт кылдым. Бер мәртәбә дә ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем. Беркайчан да: ”Бу эшне ник болай

эшләдең?” – дип ачуланганын күрмәдем”, – дигән (Мөслим).

Аллаһ расүле галәйһиссәләм күршеләрен хөрмәт иткән һәм кунакларын ихтирам белән кабул иткән. Аның Аллаһ өчен хезмәт итмәгән яки яхшы гамәл кылмаган бер генә минуты да булмаган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм киләчәккә өмет белән караган, төшенкелеккә бирелүне яратмаган. Ул ике эшнең берсен башларга кирәк булганда, аларның иң файдалысын сайлаган. Ул бәлагә төшкәннәргә ярдәм итәргә һәм мәзлүмнәрне коткарырга яраткан.

Аллаһ илчесе галәйһиссәләм үзенең сәхабәләрен бик яраткан, алар белән еш киңәшләшкән һәм алар турында кайгырткан. Әгәр сәхабәләреннән берәрсе авырып китсә, ул аларның хәлен белергә бара торган булган. Әгәр берәрсе югалып торса, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм аны эзләгән. Берәрсе вафат булса, аның хакына дога кылган. Ул һәрвакыт башкаларның гафу үтенүен кабул иткән, аның өчен көчле дә, көчсез дә үз хокукларында тигез булган. Сүз остасы буларак, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм күп төрле гыйбрәтле хикәяләр һәм тарихлар сөйли торган булган. Ул һәрвакыт дөресен генә сөйләгән.

Аллаһ расүле галәйһиссәләмнең тәрбиялеге һәм әдәплелегенә килгәндә, ул сәхабәләренә бик мәрхәмәтле, хөрмәтле мөнәсәбәттә булган, кысан җирдә һәрвакыт башкаларга күбрәк урын калдырган. Берәрсен күрсә, ул аны һәрвакыт беренче булып сәламләгән.

Аллаһ илчесе галәйһиссәләм бик тыйнак



www.darul-kutub.com

булган. Кешеләр җыелган җиргә яки җыелышка килгәч, ул урын бар җиргә утырган һәм моның белән барысының да бертигез хокуклы икәнлеген ассызыклаган. Әңгәмәдәше белән утырганда, беркайчан да аннан алда торып басмаган. Ашыккан вакытта һәрвакыт гафу үтенгән.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм беркайчан да ярлыларга фәкыйрьлекләре өчен җирәнеп карамаган, байлар алдында түбәнчелек күрсәтмәгән. Ул һәрвакыт иминлекне югары куйган. Ашаганда, эчкәндә уң кулын файдаланган, чөнки аңа Аллаһ шулай кушкан. Ул хуш исләрне яраткан: суган, сарымсак кебек начар ис таратучы нәрсәләрне сөймәгән. Аллаһ илчесе галәйһиссәләм үзенең сәхабәләреннән киеме белән дә, җыелышларда утырган урыны белән дә аерылып тормаган. Берәрсе килсә: "Ә сезнең кайсыгыз Мөхәммәд соң?" – дип сорый торган булган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм киемнәрдән ашык сөягенә кадәр җитүче озын җилән киеп йөрергә яраткан. Кием-салымда да, ризыкта да бернинди артыклыкны кабул итмәгән. Башына чалма һәм башлык кия торган булган, ә уң кулының чәнчә бармагында көмеш балдагы булган.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтте:

لَقَدْ جَاءكُمْ رَسُولٌ مِّنْ أَنفُسِكُمْ عَزِيزٌ عَلَيْهِ
مَا عَنِتُّمْ حَرِيصٌ عَلَيْكُم بِالْمُؤْمِنِينَ رَؤُوفٌ رَّحِيمٌ

*"Ий кешеләр, тәхкыйк, сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, Аллаһка карышуыгыз аңар*

*авырдыр, сезнең иманга килүегез өчен ул бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьледер"* ("Тәүбә" сүрәсе, 128нче аять).

"Күңелебездә пәйгамбәребезгә мәхәббәт бармы?" - дигән сорау бирәсе килә.

Ни өчен без бәхетсез соң? Бездән Раббыбыз канәгатьме? Тормышыбыз кая бара? Без кешеләр белән нинди мөнәсәбәттә? Без аларга ярдәм итәбезме, аларны аңлыйбызмы? Яисә без үзебез турында гына уйлыйбызмы?

Сорауларга җавап табыйк та, тормышыбызны үзгәртик, җәмәгать.

***Нияз хәзрәт Сабиров***

# Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә карата булган әдәп

Сәхабәләр сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә карата һәрвакыт әдәпле булганнар. Алар: "Без Аллаһның расүле галәйһиссәләмнең нәсыйхәтләрен тыңлаганда, күңелләребез Раббыбыз Аллаһка һәм Аның пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәләмгә карата мәхәббәт һәм әдәп белән тула иде, әйтерсең лә башларыбызга кошлар кунган һәм әгәр без хәрәкәтләнсәк, ул кошлар очып китәр иде", – дигән (Ибн Мәҗә).

Сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә сорау бирергә һәм аның күзләренә туры карарга да оялганнар. Хәтта Аллаһның расүле Мөхәммәд

галәйһиссәләм янәшәсендә еш булган сәхабәләр дә, аңа карата әдәп саклап, аның күзләренә ачык карый алмаганнар. Имам Тирмизи (Аллаһның рәхмәтендә булсын) хәбәр иткәнчә, бары тик Әбү Бәкер белән Гомәр (Аллаһ алардан разый булсын) генә аның күзләренә карап сөйләшә алганнар, калган сәхабәләр Пәйгамбәребез галәйһиссәләм белән сөйләшкәндә күзләрен читкә ала иделәр.

Гамр бин Гас (Аллаһ аннан разый булсын) үз гомеренең соңгы минутларында сөйләгән: “Мин озак вакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәләм янында тордым, ләкин аны бик хөрмәт иткәнгә һәм оялганга күрә, башымны күтәреп аңа озак карый алмадым. Әгәр бүген миннән аның йөзе турында сорасалар, ышаныгыз миңа, сөйләп бирә алмас идем”, – дигән (Мөслим).

Коръәндә пәйгамбәрләрнең исемнәре китерелгән булса да, Аллаһы Тәгалә соңгы пәйгамбәргә бер тапкыр да *“Йә Мөхәммәд”* дип мөрәҗәгать итмәде. Аллаһы Раббыбыз аңа *“Йә нәби”, “Йә Расүл”*, дип эндәште. Аллаһы Тәгалә барлык мөселманнарга Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә карата әдәпле булырга боерды. Бу турыда “Нур” сүрәсенең 63нче аятендә әйтелгән:

لَا تَجْعَلُوا دُعَاء الرَّسُولِ بَيْنَكُمْ كَدُعَاء بَعْضِكُم بَعْضًا

قَدْ يَعْلَمُ اللَّهُ الَّذِينَ يَتَسَلَّلُونَ مِنكُمْ لِوَاذًا فَلْيَحْذَرِ الَّذِينَ

يُخَالِفُونَ عَنْ أَمْرِهِ أَن تُصِيبَهُمْ فِتْنَةٌ أَوْ يُصِيبَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ

*“Бер-берегезне чакырган кебек, Пәйгамбәрне дә шулай чакырмагыз. Арагыздан бәгъзеләрегез юкны сылтау итеп, мыштым гына (рөхсәтсез) качып киткәннәрне Аллаһ белә. Аң булыгыз, Аның әмереннән качып китеп (бу дөньяда) үзегезгә фетнә-бәла чакыра күрмәгез яки (Ахирәттә) андыйларга бик хәтәр җәза китереп сугуы бар”.*

Ибн Габбас (Аллаһ аннан разый булсын) бу аять турында болай дигән: “Кешеләр Аллаһның расүле галәйһиссәләмгә “Йә Мөхәммәд”, “Йә Әбүлкасыйм” дип эндәшәләр иде. Аллаһы Тәгалә аның дәрәҗәсен күтәрер өчен, алай дип әйтергә тыйды, шуннан соң кешеләр Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә “Йә нәби”, “Йә Расүл”, дип мөрәҗәгать итә башладылар.

Бер солтан тормышыннан мисал китерәм. Габделгазиз исемле солтан авырып, урын җирендә яткан вакытта, аңа нурлы Мәдинә шәһәреннән хәбәр килә. Ул үз ярдәмчеләрен чакыртып: “Миңа аякка басырга ярдәм итегез. Мәдинә шәһәреннән килгән хәбәрне басып тыңларга тиеш. Аллаһның расүле галәйһиссәләмнең күршеләрен ятып тыңлау ярамас”, – дип әйткән. Нурлы Мәдинәдән хат килгән саен, бу солтан тәһарәтен яңартып, кулына хат алып, аны үбеп, маңгаена куеп: “Бу хатта нурлы Мәдинәнең тузаны”, - дигән һәм шуннан соң гына хатны укыган.

***Нияз хәзрәт Сабиров***

www.darul-kutub.com

# Мәүлид кичәсенең фәзыйләтләре

Хәзрәти Мәгъруф Әл-Кәрхый (Аллаһ аны үз рәхмәтеннән аермасын) әйткән: «Кем дә булса Мөхәммәд (саллаллаһу галәйһи вә сәллам) мәүлиден укытырга ризык хәзерләсә һәм мәүлидне хөрмәтләп, туган, дус-ишләрен жыйса, өен ут белән яктыртса, яңа киемен киеп, хуш исләр, хуш ислемайлар белән сөртенсә, Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә ул бәндәне Пәйгамбәрләр белән бер төркемдә булдырыр һәм (аның урыны) югары Гыйллиййиндә (җиденче күктә) булыр», дигән.

Заманының бердәнбере, гасырында берүзе (сыйфатларына карата) булучы Имам Фәхретдин Әр-Рази болай әйткән: «Мөхәммәд (саллаллаһу галәйһи вә сәллам) мәүлиден тоз, яисә бодай, яки башка бер ризык өстенә укыса шул ризыкка бәрәкәт иңер. Инде су өстенә мәүлид укылганнан соң, ул суны эчүченең кальбенә (йөрәгенә) мең нур һәм шәфкать хисләре керер, мең явызлык һәм авыру чыгып китәр. Мондый йөрәк, башка йөрәкләр үләчәк көнне үлмиячәкдер». Сүз Кыямәт көне турында бара.

Галимнәрнең солтаны Имам Жәләледдин Әс-Суйутий (Аллаһ аны үз рәхмәтеннән аермасын) болай дип әйткән: «Берәр йортта, яисә мәчеттә, яисә берәр мәхәлләдә (кварталда) Мөхәммәд (саллаллаһу галәйһи вә сәллам) мәүлиде укылса ул йортның, яисә мәчетнең, яки мәхәлләнең тирә-якларын фәрештәләр чорнап алалар һәм шушы урының халкына фәрештәләр салават әйтеп торырлар һәм

www.darulkutub.com

барысына да Аллаһы Тәгалә тарафыннан мәрхәмәт һәм Аллаһының разыйлыгы насыйп булыр. Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраил (галәйһимис-сәлам) фәрештәләр исә мәүлид укуга сәбәпче кешегә үзләре салават әйтерләр». Һәм аның хәбәр итүенчә: «Әгәр берәр мөселманның өендә мәүлид укылса, ул өйгә Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән корылык тимәс, вәба (чума) авыруы кермәс, ут тимәс, су (ташкын) тимәс, бәла-афәтләр, нәфрәт, хөсет, явыз күз, караклардан имин булыр. Әгәр мәүлид укучы бәндә вафат булса, Аллаһы Тәгалә Мөнкир вә Нәкир сорауларына җавап бирүне җиңеләйтер, һәм ул бәндә кодрәтле Аллаһы Тәгаләнең хаклык урынында булыр».

# Мәүлидне үткәрү тәртибе

## Мәүлидтә укыла торган аять-сүрәләр

***«Әл-Ихлас» сүрәсе***

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

بِسْمِ اللّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ {1} اللَّهُ الصَّمَدُ {2} لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ {3}

وَلَمْ يَكُن لَّهُ كُفُوًا أَحَدٌ {4}

www.darul-kutub.com

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим.

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим

Кульһү-әллааһү әхәде. Әллааһүс-самәде. Ләм йәлиде. Үә ләм йүүләде. Үә ләм йәкүлләһүү күфү-үән әхәде.

## *Тәкбир*

*(Бергәләшеп әйтелә)*

اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ  اَللهُ أَكْبَرُ  اَللهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ

Әллааһү әкбәр, Әллааһү әкбәр Ләәә иләәһә илләәллааһү үәллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр. Үәлилләәһил хәмде (өч тапкыр).

## *«Әл-Фәләк» сүрәсе*

بِسْمِ اللّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ {1}  مِن شَرِّ مَا خَلَقَ {2} وَمِن شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَب {3} وَمِن شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ {4} وَمِن شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ {5}

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим



www.darul-kutub.com

Куль әгүүзү бираббил фәләко. Миң шәрри мәә халәко. Үә миң шәрри гаасикыйн изәә үәкабе. Үә миң шәррин нәффәәсәәти фил-гүкаде. Үә миң шәрри хәәсидин изәә хәсәде.

### *Тәкбир*

*(Бергәләшеп әйтелә)*

اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللهُ اَللهُ أَكْبَرُ اَللهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ

Әллааһү әкбәр, Әллааһү әкбәр Ләәә иләәһә илләәллааһү үәллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр. Үәлилләәһил хәмде (өч тапкыр).

### *«Ән-Нәс» сүрәсе*

بِسْمِ اللّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ {1} مَلِكِ النَّاسِ {2} إِلَهِ النَّاسِ {3} مِن شَرِّ الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ {4} الَّذِي يُوَسْوِسُ فِي صُدُورِ النَّاسِ {5} مِنَ الْجِنَّةِ وَ النَّاسِ {6}

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим

Куль әгүүзү бираббиннәәәс. Мәликиннәәәс. Иләәһиннәәәс. Миң шәррил үәсүәәсилханнәәәс. Әлләзии йү-үәс-үисү фии судүүриннәәәс. Минәл җиннәти үәннәәәс.



www.darul-kutub.com

***Тәкбир***

*(Бергәләшеп әйтелә)*

اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللّٰهُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ اَللّٰهُ أَكْبَرُ وَ لِلَّهِ الْحَمْدُ

Әллааһү әкбәр, Әллааһү әкбәр Ләәә иләәһә илләәллааһү үәллааһү әкбәр. Әллааһү әкбәр. Үәлилләәһил хәмде (өч тапкыр).

***«Әл-Фәтихә» сүрәсе***

بِسْمِ اللّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

الْحَمْدُ للّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ {1} الرَّحْمنِ الرَّحِيمِ {2} مَلِكِ يَوْمِ الدِّينِ {3} إِيَّاكَ نَعْبُدُ وإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ {4} اهدِنَا الصِّرَاطَ المُستَقِيمَ {5} صِرَاطَ الَّذِينَ أَنعَمتَ عَلَيهِمْ غَيرِ المَغضُوبِ عَلَيهِمْ وَلاَ الضَّالِّينَ {7}

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмү лилләәһи раббил гәәләмииин. Әр-рахмәәнир-рахииим. Мәәлики йәүмиддииин. Иййәәкә нәгбүдү үә



www.darul-kutub.com

иййәәкәнәстәгииин. Иһдинәссыйрааталь мүстәкыыыйм. Сыйрааталь-ләзиинә әнгәм-тәгәләйһим. Гайрил-мәгдууби гәләйһим үәләд-дааааалииин. Әәмииин.

***«Әхзәб» сүрәсе, 40-48нче аятьләр***

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

مَّا كَانَ مُحَمَّدٌ أَبَا أَحَدٍ مِّن رِّجَالِكُمْ وَلَكِن رَّسُولَ اللَّهِ
وَخَاتَمَ النَّبِيِّينَ وَكَانَ اللَّهُ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمًا {40} يَا أَيُّهَا
الَّذِينَ آمَنُوا اذْكُرُوا اللَّهَ ذِكْرًا كَثِيرًا {41} وَسَبِّحُوهُ بُكْرَةً
وَأَصِيلًا {42} هُوَ الَّذِي يُصَلِّي عَلَيْكُمْ وَمَلَائِكَتُهُ لِيُخْرِجَكُم
مِّنَ الظُّلُمَاتِ إِلَى النُّورِ وَكَانَ بِالْمُؤْمِنِينَ رَحِيمًا {43}
تَحِيَّتُهُمْ يَوْمَ يَلْقَوْنَهُ سَلَامٌ وَأَعَدَّ لَهُمْ أَجْرًا كَرِيمًا {44} يَا أَيُّهَا
النَّبِيُّ إِنَّا أَرْسَلْنَاكَ شَاهِدًا وَمُبَشِّرًا وَنَذِيرًا {45} وَدَاعِيًا إِلَى
اللَّهِ بِإِذْنِهِ وَسِرَاجًا مُّنِيرًا {46} وَبَشِّرِ الْمُؤْمِنِينَ بِأَنَّ لَهُم مِّنَ
اللَّهِ فَضْلًا كَبِيرًا {47} وَلَا تُطِعِ الْكَافِرِينَ وَالْمُنَافِقِينَ وَدَعْ
أَذَاهُمْ وَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ وَكَفَى بِاللَّهِ وَكِيلًا {48}

www.garulkutub.com

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим.

40. Мә кәәнә Мүхәммәдүн әбәә әхәдим-миррижәәликүм үә ләәкир-расүүлә-ллаһи үә хаатәмә-ннәбиййнә үә кәәнә-ллаһү бикүлли шәйин гәлиимә. 41. Йәәәә әййүһә-лләзиинә әәмәнүүз-күруллааһә зикраң кәсиира. 42. Үә сәббихүүһү бүкратәү-үә әсыыйлә. 43. Һү-үәлләзии йүсаллии гәләйкүм үә мәләәәә икәтүһүү лийүхрижәкүм минәззулүмәәти илә-ннүүүр үә кәәнә билмүъминиинә рахиимә. 44. Тәхиййәтүһүм йәүмә йәлкаунәһүү сәләәәм үә әгәддә ләһүм әжраң кәриимә. 45. Йәәәә әййүһән-нәбиййү иннәәә әрсәлнәәкә шәәһидәү үә мүбәшшираү үә нәзиира. 46. Үә дәәгийән илләллааһи би'изниһии үә сираажәм-мүниира. 47. Үә бәшширил-мүъминиинә би'әннә ләһүм минәллааһи фәдләң кәбиира. 48. Үә ләә түтыйгил-кәәфириинә үәл мүнәәфикыыйнә үә дәг әзәәһүм үә тәүәккәл гәләллааһи үә кәфәә биләәһи үәкиилә.

# Саләүәәтүл макбүүлә

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

إِنَّ اللَّهَ وَمَلَآئِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا

اَللّهــــُمَّ صَلِّ عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ سَيِّدِ الْعَرَبِ وَالْعَجَمِ. وَاِمَامِ مَكَّةَ وَالْمَدِينَةِ الْمُنَوَّرَةِ وَالْحَرَمِ. وَتَرْجُمَانِ لِسَانِ السَّلَفِ وَالْكَرَمِ. وَعَلَّمَ الْاِنْسَانَ مَالَمْ يَعْلَمْ. أَصْلُهُ نُورٌ وَنَسْلُهُ آدَمُ. بَعْثُهُ مُؤَخَّرٌ وَخَلْقُهُ مُقَدَّمٌ. إِسْمُهُ الشَّرِيفُ مَكْتُوبٌ عَلَى اللَّوْحِ الْمَحْفُوظِ بِيَاقُوتِ الْجَوْهَرِ وَالْقَلَمِ. جِسْمُهُ الشَّرِيفُ مَدْفُونٌ فِى الْمَدِينَةِ الْمُنَوَّرَةِ وَالْحَرَمِ. فَطُوبَى، ثُمَّ طُوبَى لِمَنْ رَآهُ وَتَابَعَهُ وَلِمَنْ أَسْلَمَ. مَنْبَعُ الشَّفَاعَةِ يَوْمَ الْحَشْرِ وَالنَّدَمِ. وَمَنْبَعُ الشَّفَاعَةِ لِلْعَاصِينَ قَآئِلاً: يَا رَبِّ سَلِّمْ. يَوْمَ يَا لَيْتَ اكْتَحَلْنَا تُرَابَ تَحْتِ الْقَدَمِ. يَوْمَ يَقُولُ: اُمَّتِى، اُمَّتِى، وَا اُمَّتَاهْ، يَا ذَى الُّلطْفِ وَالْكَرَمِ. فَيُنَادِى الْمُنَادِى مِنْ قِبَلِ الرَّحْمَانِ الْاَرْحَمِ. قُبِلَتْ شَفَاعَتُكَ يَا نَبِيِّ الْمُحْتَرَمِ. اُدْخُلُوا الْجَنَّةَ لاَ خَوْفٌ عَلَيْكُمْ وَلاَ حَزَنٌ وَلاَ اَلَمٌ. ثُمَّ رَضِيَ اللّٰهُ تَعَالَى عَنْ أبِى بَكْرٍ وَعَنْ عُمَرَ وَعَنْ عُثْمَانَ وَعَنْ عَلِيٍّ ذَوِى الْكَرَمِ. ثُمَّ رَضِيَ اللّٰهُ تَعَالَى عَنْ خَادِمِ الشَّرِيعَةِ الْاِمَامِ الْأَعْظَمِ. وَصَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ. وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ. وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ. مِنْ

اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرْضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

سُبْحَانَ رَبِّكَ رَبِّ الْعِزَّةِ عَمَّا يَصِفُونَ * وَسَلاَمٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ* وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الآخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

Әгүүзү билләәhи минәш-шәйтаанир-ражииим.

Иннәллааhә үә мәләәәә-икәтәhүү йүсаллүүнә гәләннәбиййи, йәәәә әййүhә-ллэзиинә әәмәнүү саллүү гәләйhи үә сәллимүү тәслиимә. (“Әхзәб” сүрәсе, 56 аять).

Әллааhүммә салли гәләә сәййидинәә Мүхәммәдиң сәййидил гәраби үал гәҗәм. Үә имәәми Мәккәтә үәл Мәдиинәтил мүнәүүәрати үәл хәрам. Үә тәрҗүмәәни лисә-әниссәлә-фи үәл кәрам. Үә гәлләмәл иңсәәнә мәә ләм йәгләм. Әслүhүү нүүрүү үә нәслүhүү әәдәм. Бәгсүhүү мү әххарүү үә халькуhүү мүкаддәм. Исмүhүш шәриифү мәктүүбүң гәләл ләүхил мәхфүүзый би йәәкуутил җәүhәри үәл каләм. Җисмүhүш шәриифү мәдефүүнүң фил Мәдиинәтил мүнәүүәрати үәл хәрам. Фәтуубәә суммә туубәә лимәррааahү үә тәәбәгәhү үә лимән әсләм. Мәмбәгүшшәфәәгәти йәүмәл хәшри үәннәдәм. Үә мәмбәгүшшәфәәгәти лилгәәсыыйнә каааа иләй йәәраббәссәләм. Йәүмә йәә ләйтә иктәхәлнәә түраабә тәхтил кадәм. Йәүмә йәкуулү үммәтии үммәтии үә үммәтәәh йәәзәл лүтфи үәлкәрам. Фә йүнәәдил

мүнәәдии миң кыйбә-лиррахмәәнил әрхәм. Кубиләт шәфәәгәтүкә йә нәбиййи-әл мүхтәрам. Үдхулүл җәннәтә ләә хаүфүн гәләйкүм үә ләә хәзәнүү үә ләә әләм. Сүммә радыйә-ллааһү тәгәәләә гән Әбии Бәкриү үә гән Гүмәра үә гән Гүсмәәнә үә гән Гәлиййи зәүил кирам. Сүммә радый-әллаһү тәгәәләә гән хаадимиииш шәриигәтиһил имәә-мил әгзам. Үә салләллааһү тәгаалә гәләә җәмиигил әмбийәәәә и үәл мүрсәлиинә үә гәләә мәләәикәтикәл мукаррабиин. Үә гәләә әһли таагәтикә әҗмәгыйн. Мин әһлис ссәмәәүәәти үәл әрдыйн. Үәрхәмнәә үәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр рраахимиин. Сүбхәәнә раббикә раббил гиззәти гәммә йәсыйфүүн үә сәләәмүн гәләл мүрсәлиин үәлхәмдүлилләәһи раббил-гәәләми-иин.

Раббәнәә әәтинәә фиддүнйәә хәсәнәтәү үә фил әәхыйрати хәсәнәтәү үә кыйнәә гәзәәбән-нәәәр.

# Расүл әкрамның нәсел - нәсабы шәрифе

Дүртесенең исмене белмәк важип, *(тиешле)*
Әһле инсан (кешеләр) санадылар ап – ачык.
Габдулла иде Мөхәммәд атасы,
Габделмуталлиб иде һәм бабасы.
Һашим иде ул баба өченчесе,
Габдеманаф булды тәмам дүртесе.
Сабыр итегез, хәзер әйтәм калганын,
Бишенчесе иде Кусай, бабаның.
Алтынчысының иде исме Киләп,
Мурратдыр җиденчесе, би – инкыйлап. *(үзгәрешсез)*

Сигезенчесе Кәгъб иде бабаларның,
Һәм Лүъәйдер тугызынчысы аның.
Исме Гаалибдыр унынчы бабаның,
Унберенчесе Фиһрдер, бел, аның.
Уникенчесе Мәликтер, исме шәп,
Унөченчесе Надрдер, кылма шәк. *(шикләнмә)*
Ундүртенчесенең исме Кинанә,
Ки унбишенчесенеңдер, Хузәймә.
Ки Мүдрикәдер уналтынчы, бәс,
Ки унҗиденчесенең исме Ильяс.
Мудар унсигезенчедер бабаның,
Низар унтугызынчыдыр, бел, аның.
Мәгадь инде егерменче бабадан,
Егерме бер тәмам булды ки, Гаднән.

*Болардан башкалары Исмәгыйль галәйһиссәләмгә кадәр бик ачык мәгълүм түгелдер.*

## “Мәүлидүн-нәби” касыйдәсе

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим
Әүвәл Аллаһ исмен зикер итәем,
Соңра башлап, һәр эшкә керешәем!
Эш башында кем аны зикер итәр,
Ул эшен Аллаһ аңа ансат итәр.
Аллаһ исмен зикер итеп эш башламак,
Һәркемгә важип тиештер аңламак.
Булса Аллаһ исме берлә һәр эшең,
Бушка китмәс эшләгән һәрбер эшең!
Шаукъ илә “Аллаһ” дисә кемнең теле,
Барча гөнаһы түгелер яфрак кебек!

Пакь булыр Аллаһ исмен зикер иткән,
Ирешер максадына “Аллаһ” дигән!
Килегез, чын күңелдән “Аллаһ!” диик,
Күзләрдән яшьләр түгеп без аһ итик.
Шулай итсәк, буш куймас Аллаһ безне,
Рахмәте киң, ярлыкар һәммәбезне.
Бердер Аллаһ, берлегенә шөбһә юк,
Сөйләгәннәр ялгышып – дөнья тулук.
Барча галәм юк икән, Ул бар иде,
Һәм әзәлдән бай иде, Җәббар иде.
Җен – фәрештә һәм адәм – берсе дә юк,
Һәм янә тугыз фәләк – һичберсе юк!
Гарше – көрси, ай – кояш һәм юк иде,
Барча җаннан әүвәл ук Ул бар иде.
Кодрәт белән боларны бар әйләде,
Берлегене барча икърар әйләде.
Бу хосуста күп сүзгә хаҗәт тә юк,
Аллаһ бердер, бардыр Ул, башкасы юк!
Әгәр шәфәгать кирәк исә эзләгез,
Ул Расүлнең сөннәтеннән бизмәгез.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

## *Мәүлид мөнәҗәтләре*

Рәсүлүлла намазда ул
Башындадыр аның таҗы
Өммәти, өммәти диеп
Агадыр күзендин яше.

Рәсүлүлла раузасында
Зикер әйтеп сайрый кошлар
Шул кошлардан гыйбрәт алып



www.darul-kutub.com

Салаватлар әйтик дуслар.

Салаватларга кушылыгыз
Салаватларын белгәннәр
Җәннәт ишеген ача алмаслар
Салаватлар әйтмәгәннәр.

### *Салават*

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Расүүләллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Нәбийәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Хәбиибәллааһ.
Әссаләәтү үәс-сәляямү, галәйкә,
йә, Хайра Халькыйлләәһ.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Сәййдәль-Әүүәлиинә үәль-Әәхыйриин.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Рахмәтәл лиль-гәәләмиин.

* * *

Әй газизләр, инде килде сүз башы,
Тыңлагыз сез агызып күз яше.
Бер васыять сөйләмәкче буламын,
Ул васыять ошбудыр тот колагың.
Һәркем аны тыңласа, тотар исә,
Ул кешедән һәрзаман хушбуй исә.
Кылыр Аллаһ шул кешегә рахмәтен,
Мәүледин-нәбинең кылса хөрмәтен.
Тыңлаганнар һәм табыр фазыйләтен,



www.darul-kutub.com

Укыса нәсел-нисап шамаилен!
Рухыны шат итәек саләт илә,
Әhле бәйте, әсхабләр беләң бергә.
Ул туган көннәрене хөрмәт иткән,
Тыңлар шул кыйссасыны ихлас беләң.
Ий Мөхәммәд Мостафа син, ий Расүл,
Кыл шәфәгать безләргә яүмүн-нүзүл.

## *Мәүлид мөнәҗәтләре*

Рәсүлүлла намазда ул
Башындадыр аның тажы
Өммәти, өммәти диеп
Агадыр күзендин яше.

Рәсүлүлла раузасында
Зикер әйтеп сайрый кошлар
Шул кошлардан гыйбрәт алып
Салаватлар әйтик дуслар.

Салаватларга кушылыгыз
Салаватларын белгәннәр
Җәннәт ишеген ача алмаслар
Салаватлар әйтмәгәннәр.

## *Салават*

Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Расүүләллааh.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Нәбийәллааh.
Әссаләәтү үәс-сәләәмү, галәйкә,
йә, Хәбиибәллааh.